ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«БОЕРГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕК СОВЕТЫ

# КАРАР

"13" октябрь 2020 ел Боерган авылы № 3/2

**«Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Советының 2019 елның 06 декабрь 51/3 санлы «2020 елга, 2021 һәм 2022 елларның план чорына Боерган авыл җирлегенең бюджеты турында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында»**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм «Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Советының 2019 елның 06 декабрь 51/3 санлы «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар планы чорына Боерган авыл җирлегенең бюджеты турында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» мәгълүматны тыңлап, муниципаль берәмлек Советы

## КАРАР КЫЛДЫ:

1. Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Советының 2019 елның 06 декабрь 51/3 санлы «2020 елга, 2021 һәм 2022 елларның план чорына Боерган авыл җирлегенең бюджеты турында» карарына (Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Советының 26.05.2020 ел № 53/3 карары белән аңа кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 маддә 1 пункт 1 пунктчада «4636,35» саннарын «6454,05» саннарына алыштырырга,
- 1 маддә 1 пункт 2 пунктчада «4648,62» саннарын «6466,32» саннарына алыштырырга,

2. Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Советының 2019 елның 06 декабрь 51/3 санлы «2020 елга, 2021 һәм 2022 елларның план чорына Боерган авыл җирлегенең бюджеты турында» карарының 1, 3, 7, 9, 11 кушымталарын яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегенә урнаштырырга.

5. Әлеге карар халыкка рәсми игълан ителгәннән соң, законлы көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе Ф.В.Шәйхразиев